**Шәһәр күләмендә җәмгыять белеме фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре**
**2025-2026 нчы уку**
**елы 8-9 нчы**
**сыйныф**

**Эш вакыты – 120 минут**
**Гомуми балл – 84**

**1. Сорауларга җавап бирегез. Дөрес җавапны сайлап билгеләгез. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 5 балл.**

**1.1. Дамир юлны кызыл утка чыга. Дамир бу очракта кайсы хокук нормасын боза?**

1) Юл хокукларын

2) Җинаять хокукларын

3) Административ хокукларны

4) Гражданлык хокукларын

5) Гаилә хокукларын

**1.2. Бүгенге көндә Татарстан Республикасы башлыгын ничек атап йөртәләр:**

1) президент

2) глава

3) рәис

4) каган

**1.3. Конституция нигезендә Россия презеденты ничә елга сайлана?**

1) 5

2) 4

3) 6

4) 7

**1.4. Ата-аналардан һәм аларның кияүгә чыкмаган (өйләнмәгән) балаларын үз эченә алган гаилә ничек атала?**

1) киңәйтелгән

2) периферияле

3) нуклеар

4) күп буынлы

**1.5. Казан гербында нәрсә сүрәтләнгән?**

1) Ак барс

2) Елан (Зилант)

3) Бүре

4) Аккош

**2. Курсив белән билгеләнгән җирне җәмгыять белеме атамасы белән алыштырыгыз. Дөрес җавап өчен 2 балл. Барлыгы 6 балл.**

2.1. Советлар хакимияте вакытында төп дини тәгълимат булып *Аллаһка ышанмау* иде.

**Җавап:** _____

2.2. Бүгенге көндә базар икътисады шартларында *көндәшлек, яхшы нәтиҗәләргә ирешү өчен көрәш* җитештерүчеләрне үз товарларын камилләштерергә, чикләнгән ресурсларны файдалануның нәтиҗәлерәк юлларын эзләргә этәрә.

**Җавап:**_____

2.3. Сталин чоры халыкка каршы массачыл террор, куәтле җәза системасын булдырган һәм кырыс *бөтен хакимиятне үз кулында туплаган* режим буларак тарихта канлы эз калдырды.

**Җавап:**_____

**3. Биремнәрне үтәгез. Әгәр сезнең җавабыгыз түбәндәге гыйбарә белән туры килсә, <u>әйе</u>, туры килмәсә, <u>юк</u> дип билгеләгез. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 5 балл.**

3.1. Толерантлык ул чит кешеләрнең тормыш рәвешенә, гореф-гадәтләренә, дини ышануларына битараф караш.

3.2. Тулы кыйммәтсезлек комплексы ул үзеңнең ниндидер кимчелекләреңне тотрыклы рәвештә тою хисенең бәйләнчек идеягә әверелүе.

3.3. Хәзерге Россиядә кайбер җинаятьләргә карата атып үтерү җәзасын куллану торгызылды.

3.4. 2026 елда М.Ш.Шәймиевны Татарстан Республикасы президенты итеп сайлауга 30 ел була.

3.5. Политология фәне демография проблемаларын өйрәнү белән шөгыльләнә.

Җавап:

| 3.1. | 3.2. | 3.3. | 3.4. | 3.5. |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**4. Хокук бозу мисаллары һәм юридик җаваплылык төрләре арасында тәңгәллекне билгеләгез. Җавабыгызны таблицага язып куегыз. Дөрес тәңгәллек өчен 1 балл. Барлыгы 5 балл.**

| Хокук бозу мисаллары | Юридик җаваплылык төрләре |
|---|---|
| 1) Машина йөртүче А тизлекне арттыру аркасында койманы вата | А. Җинаять эше |
| 2) Гражданин А үз милке булган бакчасындагы койманы күчереп, күршеләргә электр щитына юлны каплый | Б. Административ |
| 3) Гражданиннар А һәм Б милли тыюлыкта (заповедник) җәнлек (кош-корт) аулыйлар | |
| 4) Яшүсмерләр футбол уеныннан соң кибетнең пыяласын ватып, витринадан берничә шешә исерткеч эчемлек урлыйлар | |
| 5) Гражданин Б гражданин Вның аягына суга. Нәтиҗәдә соңгысының сәламәтлегенә артык зыян килми, бары тик каты физик авырту кичерә | |

Җавап:

| 1. | 2. | 3. | 4. | 5. |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**5. Түбәндәге ситуацияләрне хокук нормалары күзлегеннән чыгып анализлагыз. Барлыгы 5 балл.**

**5.1.** Күптән түгел генә яңа гаилә барлыкка килә. Ләкин яшьләр арасында тормышның беренче көненнән үк кайбер мөһим сорауларда аңлашылмаучанлык һәм фикер төрлелеге барлыкка килә. Бу түбәндәгеләрдә чагыла:

- ул (гаилә башлыгы) гаиләсе белән зур шәһәрдә яшәргә теләк белдерә, ә аның хатыны киресенчә, даими яшәү урыны булган тыныч шәһәрдә әти-әниләре белән яшәргә ниятли;
- ул хатынына эшен ташларга һәм бары йорт эшләре белән шөгыльләнергә тәкъдим итә, ә хатыны киресенчә үз белгечлеге буенча эшен дәвам итүне кирәк дип саный.

**Ир белән хатын үз сорауларына җавап табар өчен һәм кем гаиләдә төп сүзгә ия булуын белер өчен Гаилә кодексына мөрәҗәгать итәләр. Сезнеңчә үзләре өчен алар нинди җавап табарлар? (3 балл)**

_____
_____
_____
_____

**5.2. Туачак баланың әнисе Россия гражданы, ә әтисе чит илнеке. Нинди шартта туачак бала Россия гражданы булачак? (2 балл)**

_____
_____
_____
_____

**6. Бирелгән үрнәкләрне һәм белем бирү баскычларын билгеләгез. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 5 балл.**

| | **Үрнәкләр** | | **Белем бирү баскычлары** |
|---|---|---|---|
| **А)** | Укучы предпрофиль электив курска язылды | 1) | төп гомуми белем бирү |
| **Б)** | Студент колледжда автомеханик белгечлеген ала. | 2) | урта махсус белем бирү |
| **В)** | Укучы музыкаль мәктәпкә йөреп сольфеджиода уйнарга өйрәнә | 3) | өстәмә белем бирү |
| **Г)** | Укытучы квалификацияне күтәрү курсларына йөри. | | |
| **Д)** | Укучы укудан соң халык һөнәрләре студиясенә йөри | | |

Җавабыгызны таблицага саннар белән языгыз:

| **А** | **Б** | **В** | **Г** | **Д** |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**7. Икътисади мәсьәләне чишегез. Барлыгы 5 балл.**

Нияз икътисад буенча дәреслек укып, баету нияте белән 2000 сум акчасын җыеп банкка алып килә. Әлеге банкта ике төрле кертем ясау мөмкинлеге бар:

- “Байлык”, әлеге вариант буенча ярты елга 10% кертем каралган (җыелган процентларны истә тотып);

- “Мөмкинлек”, әлеге вариант буенча суммага дүрт атнага бер тапкыр 20 сум өстәлә. Әгәр елда 52 атна дип санасак, рациональ булган Нияз банктан нинди сумма алачак?

**Җавап:**_____

_____

_____

_____

**8. Сезнең алда документ. Сорауларга җавап бирегез. Барлыгы 8 балл.**




***Сораулар:***

***1. Әлеге документ ничек атала?(2 балл)***

_____

***2. Әлеге документ кайчан кабул ителә (көн, ай һәм елын языгыз)? (2 балл)***

_____

***3. Әлеге документ кайсы оешма тарафыннан кабул ителде? (2 балл)***

_____

***4. Кеше ничә яшькә кадәр бала булып санала? (2 балл)***

_____

**9. Түбәндә китерелгән текстны укыгыз һәм хаталарны табыгыз. Тапкан хаталар урынына дөрес җавап вариантын язып куегыз. Тапкан хата өчен 1 балл. Дөресләп төзәткән өчен 2 балл. Барлыгы 21 балл.**

Сайлау хокукы гомуми була. 21 яшькә җиткән һәр граждан социаль хәле, җенесе, милләте, тоткан дине, белеме нинди булуга карамастан сайлый ала. Моннан тыш аерым билгеләнгән урыннарда суд карары буенча ирегеннән мәхрүм ителгәннәр һәм суд тәртибендә сәләтсез дип табылганнар да сайлау хокукына ия.

Сайлау хокукы тигез була: һәр сайлаучы берничә тавышка ия.

Россия Федерациясендә күпбаскычлы сайлаулар алып барыла. Мондый тәртипләр белән Президентны, Дәүләт Думасын сайлыйлар. РФ Президенты – 5 елга, Дәүләт Думасы – 5 елга сайлап куела.

РФ Конституциясе нигезендә дебатларны узган граждан дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына сайлану хокукына ия. Дөрес, хакимият органнарына сайлануда яшь цензы зуррак булырга мөмкин. Дәүләт Думасына сайлану өчен – 30 яшь, РФ Президенты итеп сайлану өчен – 35 яшь. Мондый тәртиптә гражданнар кандидатлар арасыннан иң лаекларын сайлап алалар.

**Җавап:**

| | Хата | Төзәтү |
|---|---|---|
| 1. | | |
| 2. | | |
| 3. | | |
| 4. | | |
| 5. | | |
| 6. | | |
| 7. | | |

**10. Татарстан Республикасының Дәүләт Конституциясе 7 бүлектән тора. Әлеге бүлекләрне хронологик тәртиптә урнаштырыгыз. Дөрес җавап өчен 4 балл. Бер хата булган очракта 3 балл. Икедән артык хата бәяләнми.**

1) Дәүләт хакимияте оештыру

2) Конституцион тәзелеш нигезләре

3) Кеше һәм гражданнарның төп хокуклары, ирекләре һәм бурычлары

4) Җирле үзидарә

5) Административ-территориаль төзелеш

6) Дәүләт символлары һәм Татарстан Республикасы башкаласы

7) Татарстан Республика Конституциясен кабул итү тәртибе һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

Җавап: _____

**11. Түбәндә берничә илнең флаглары күрсәтелгән. Аларның хәзерге көндә дәүләт төзелеше формасын билгеләгез. Җавапны таблицага языгыз. Дөрес җавап өчен 1 балл. Барлыгы 5 балл.**

| | |
|---|---|
| А. | Б.  |
| В.  | Г. |
| Д. | |

1) Федератив дәүләт

2) Унитар дәүләт

Җавап:

| **Дәүләт флагы (хәреф)** | А | Б | В | Г | Д |
|---|---|---|---|---|---|
| **Дәүләт төзелеше формасы (сан)** | | | | | |

**12. Сезнең алда Татарстан республикасының сәяси тормышындагы төп вакыйгалар күрсәтелгән. Беренче баганадагы вакыйгаларны икенче баганада бирелгән даталар белән туры китерегез. Даталарның артык булуына игътибар итегез. Билгеләнгән һәр дөрес тәңгәллек өчен 2 балл. Барлыгы 10 балл.**

| **Вакыйгалар** | **Даталар** |
|---|---|
| 1) ТР Президенты итеп Р.Н. Миннихановны сайлау | А) 2005 елның 30 августы |
| 2) Казанның меңъеллыгын бәйрәм итү | Б) 2010 ел |
| 3) Казан Кремлендә Кол Шәриф мәчетен ачу | В) 2024 ел |
| 4) БРИКС саммиты | Г) 2008 ел |
| 5) Казан Бөтендөнья җәйге Универсиадасының башкаласы итеп билгеләнде | Д) 2013 ел |
| | Е) 2005 елның 24 июне |

Җавап:

| 1. | 2. | 3. | 4. | 5. |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |